# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Халыкны эш белән тәэмин итү турында"
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Югары Советы КАРАР БИРӘ:

"Халыкны эш белән тәэмин итү турында" Татарстан Республикасы Законына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1 статья. Керешнең беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Әлеге Закон халыкны эш белән тәэмин итүнең хокукый, икътисадый һәм оештыру шартларын, шулай ук Татарстан Республикасы гражданнарының хезмәткә хокукларын гамәлгә ашыруда дәүләт гарантияләрен билгели";

2 статья. 2 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"...үзләрен мөстәкыйль рәвештә эш белән тәэмин итүче гражданнар, моңа эшкуарлар, шәхси хезмәт эшчәнлеге белән шөгыльләнүче 0,25 гектар һәм аннан да күбрәк ярдәмче хуҗалыгы булган затлар, фермерлар, җитештерү кооперативлары әгъзалары

керә;".

Алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"...хезмәткә сәләте булган гражданнар, гомуми белем мәктәпләрендә, техник һөнәр училищеларында, махсус урта, югары һәм башка уку йортларында көндез белем алучылар, эш белән тәэмин итүнең дәүләт хезмәте юлламасы буенча белем алуны да кертеп".

3 статья. 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3 статья. Гражданнарны эшсезләр дип тануның тәртибе һәм шартлары

Хезмәткә яраклы яшьтә булып та, эше, хезмәт хакы һәм башка кереме булмаган, үзенә яраклы эш эзләү максатында хезмәт органнарында һәм эш белән тәэмин итү органнарында теркәлгән һәм эшкә керешергә әзер булган хезмәткә сәләтле гражданнар эшсезләр дип таныла. Бу вакытта дәүләтнең эш белән тәэмин итү хезмәте юлламасы буенча җәмәгать эшләрен башкарган өчен түләү, шулай ук предприятиеләрне, учреждениеләрне, оешмаларны бетерү, үзгәртеп кору, хезмәткәрләр санын яисә штат кыскарту белән бәйле рәвештә җибәрелгән хезмәткәрләргә бирелә торган пособиеләр һәм уртача хезмәт хакы түләүләре исәпкә алынмый.

Гражданны эшсез дип тану турында карар эш белән тәэмин итүнең дәүләт хезмәтенә паспорт, хезмәт кенәгәсе яисә аларны алмаштыручы документлар, аның һөнәре буенча белгечлеген раслаучы документлар, соңгы төп эш урыны буенча аздактагы өч ай өчен уртача хезмәт хакы турында белешмәләр, аның тәрбиясендә булу-

чыларны раслый торган белешмәләр һәм законнарда билгеләнгән башка кирәкле документлар бирелгән мизгелдән башлап 11 көннән дә соңга калмыйча гражданның яшәү урыны буенча эш белән тәэмин итүнең дәүләт хезмәте тарафыннан кабул ителә. Беренче мәртәбә эш эзләүче һәм һөнәре (белгечлеге) булмаган гражданнар паспорт һәм белем турында документлар күрсәтәләр.

Түбәндәге гражданнарны эшсезләр дип танып булмый:

16 яшенә җитмәгән гражданнар;

хезмәт органнарында һәм эш белән тәэмин итү органнарында теркәлгәннән соң 10 көн дәвамында тәкъдим ителгән яраклы эштән баш тартучылар;

һөнәр өйрәтүдән - ике тапкыр яисә тәкъдим ителгән түләүле эштән бер тапкыр баш тарткан (вакытлыча эшне дә кертеп), һөнәре (белгечлеге) булмаган беренче тапкыр эш эзләүчеләр. Гражданга бер үк эш һәм һөнәргә (белгечлеккә) өйрәнү ике мәртәбә тәкъдим ителми;

пенсия турында законнар нигезендә билгеләнгән тәртиптә дәүләт пенсиясе (ташламалы шартлардагы пенсияне дә кертеп) алырга хокукы булганнар, өченче төркем гариплек буенча пенсионерлар монда керми.

Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылмаган граждан үзен эшсез дип таныту өчен ике атнадан соң хезмәт органнарына һәм эш белән тәэмин итү органнарына кабаттан мөрәҗәгать итәргә хаклы".

<u>4статья.</u> 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<u>"4 статья.</u> Яраклы һәм яраксыз эш

1. Хезмәткәрнең һөнәренә, кәсби әзерлек дәрәҗәсенә, аның элеккеге эшенә, сәламәтлегенә туры килерлек, эш урынына транспортта барып җитәрлек эш яраклы дип санала.

Эшсезнең яшәү урыныннан яраклы эшкә кадәр юлы, әлеге урындагы җәмәгать транспорты челтәре үсешен исәпкә алып, халык депутатларының тиешле җирле Советы тарафыннан билгеләнә.

Алдан әзерлекне таләп итүче яисә итмәүче һәм хезмәт турында законнар таләпләренә җавап бирә торган түләүле эш (вакытлыча эшне дә кертеп) гражданнарның түбәндәге категорияләре өчен (яшьләрен һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алып) яраклы эш дип санала:

- беренче тапкыр эш эзләүче, һөнәре (белгечлеге) булмаганнар;

- өч ел эшләмичә торганнан соң яисә эшсезлекнең башлангыч (12 ай) чорыннан соң белгечлеген арттырудан (кире кайтарудан) яисә эргәдәш һөнәр (белгечлек) алудан баш тартучылар.

2. Әлеге категория гражданнар өчен эш яраксыз дип санала, әгәр:

- граждан белән килешмичә генә яшәү урынын алмаштыру белән бәйле булса;

- хезмәт шартлары хезмәтне саклау турындагы кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килмәсә".

<u>5 статья.</u> 5 статьяның икенче абзацында "хезмәткә сәләтсез" дигән сүзләрне "хезмәткә сәләтле" дигән сүзләргә алмаштырырга.

<u>6 статья.</u> 6 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Эш белән тәэмин итү турындагы законнар, әгәр законнарда башкасы каралмаган булса, Татарстан Республикасы гражданнарына, Татарстан Республикасында кимендә алты ай даими

яшәүче чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга кагыла".

7 статья. 6 статьяның искәрмәсендә "гариплар" сүзе алдыннан "өченче төркем" дигән сүзләрне өстәргә.

8 статья. 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8 статья. Гражданнарның кәсби консультация алу, эшкә әзерләү, яңа эшкә өйрәнү һәм белгечлек алу хокукы

Гражданнар дәүләтнең эш белән тәэмин итү хезмәтендә эш төрен, һөнәрен, эш урынын, хезмәт режимын һәм шартларын, эшкә өйрәнү мөмкинлекләрен сайлау максатында бушлай консультация һәм бушлай мәгълүматлар алырга хаклы.

Эшсез гражданнарның хезмәт органнары һәм эш белән тәэмин итү органнары юлламасы буенча шулай ук бушлай һөнәр эзләү, эшкә әзерләнү, яңа һөнәр үзләштерү хокукы бар".

9 статья. 11 статьяда дүртенче абзац ахырында нокталы өтер урынына нокта куярга.

Статьяның дүртенче абзацыннан соң түбәндәге редакциядәге бишенче абзац өстәргә:

"Дәүләт эшсез гражданнарга түбәндәгеләрне гарантияли:..."

Бишенче абзацны алтынчы абзац дип санарга һәм түбәндәгечә бәян итәргә:

"...бушлай яңа һөнәргә (белгечлеккә) өйрәнү,хезмәт органнары һәм эш белән тәэмин итү органнары юлламасы буенча, стипендия алып, белгечлеген арттыру".

98

10 статья. 12 статьяның 1 пунктында "югарыда күрсәтелгән гражданнарны эшкә алу өчен" дигән сүзләрдән соң өтерне һәм "шул исәптән гариплләр өчен" дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

11 статья. 15 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

" 15 статья. Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү һәм халыкны җәмгыяви яклау программалары

Дәүләтнең хезмәт органнары һәм эш белән тәэмин итү органнары әлеге Закон нигезендә халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү һәм эшсез калган халыкны җәмгыяви яклау гамәлләрен күз алдында тотучы республика һәм төбәк программалары әзерлиләр һәм аларны Татарстан Республикасы Югары Советы, халык депутатларының җирле Советлары карамагына кертәләр һәм алар белән бергә программаларны гамәлгә ашыруны тәэмин итәләр".

12 статья. 19 статьяда "Хезмәт органнары һәм эш белән тәэмин итүнең дәүләт органнары" дигән сүзләрне "Хезмәт һәм җәмгыяви мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитетының эш белән тәэмин итү идарәсе ия..." дип алмаштырырга.

13 статья. 23 статьяда 1 пунктның беренче абзацындагы "Хезмәт һәм эш белән тәэмин итү органнарында эш эзләүче сыйфатында теркәлгән кешеләрне" дигән сүзләрне "эшсез гражданнар" дигән сүзләр белән алмаштырырга;

1 пунктның бишенче абзацын төшереп калдырырга.

14 статья. 24 статьяның өченче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Җәмәгать эшләрен финанслау әлеге эшләр алар өчен башкарыла торган предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар исәбенә, шулай ук тиешле җирле бюджет исәбенә һәм Татарстан Республикасының Эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фонды акчасына үткәрелә".

<u>15 статья.</u> 27 статьяда соңгы абзац ахырындагы нокта урынына нокталы өтер куярга һәм түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

"...эш бирүчеләрдән эш белән тәэмин итү фондына яшереп калдырылган яисә киметелгән иминлек кертемнәрен, шулай ук салымның түләнми калган өлешен (недоимканы), законнарда каралган штрафларны һәм башка җәза рәвешендәге түләүләрне эзләтеп алырга. Күрсәтелгән суммалар эш бирүче белән бюджет арасында исәп-хисап ясалганнан соң тотып калына. Бу суммаларны тотып калганда эш белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте үз вакытында салым органнарына кертелмәгән салымнарны эзләтеп алу буенча бирелгән хокуклардан файдалана".

<u>16 статья.</u> 28 статьядагы пунктларның номерларына үзгәрешләр кертергә һәм статьяны 2 пункттан башлап түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Эш бирүчеләр хезмәт органнарына һәм эш белән тәэмин итү органнарына буш эш урыннары (вакант урыннар), эшче көчләргә ихтыяҗ, эшкә алу шартлары турында Статистика буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты тарафыннан расланган үрнәктә билгеләнгән вакытка тулы һәм дөрес мәгълүматлар бирәләр.

3. Эш бирүчеләр хезмәткәрләрнең күпләп эштән чыгарылу их-

тималы турында, моңа әлегергә мөмкин булган хезмәткәрләрнең саны һәм категорияләре турында, аның гамәлгә ашырылу вакытын язма рәвештә кимендә өч ай алдан тулы күләмдә хезмәт органнарына һәм эш белән тәэмин итү органнарына, профсоюз органына билгеләнгән рәвештә мәгълүматлар бирәләр, ялган мәгълүматлар биргән өчен, шулай ук мәгълүматлар бирмәгән өчен гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә җавапка тартылалар.

4. Эш бирүчеләр әлеге җитештерү урынында кәсби авыру алган яисә гарипләнгән хезмәткәрләрне эшкә урнаштыру уңаеннан махсус эш урыннары булдыру һәм һөнәр бирү буенча дәүләтнең эш белән тәэмин итү хезмәте тоткан чыгымнарны, шулай ук хезмәт органнары һәм эш белән тәэмин итү органнары аша шартнамә нигезендә һөнәр алуга өзерлек үткән затларны эшкә алудан баш тарткан очракта, укыту өчен тотылган чыгымнарны, стипендия түләүләрен дә кертеп, эш белән тәэмин итү фондына акча күчерү юлы белән тулысынча кайтаралар.

5. Югары, махсус урта һәм техник һөнәр уку йортларын бетергәннәр өчен алдан гариза бирелгәннәрне, шулай ук җәмгыяви яклауга зәруча мохтаҗ кешеләр өчен махсус эш урыннары булдыруга җирле хакимият органнары тарафыннан билгеләнгән квотаны үтәмәгәндә, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар эш белән тәэмин итү фондына шушы предприятиедә, учреждениедә һәм оешмада хезмәткәрнең уртача еллык эш хакы күләмендә максатчан финанс кертемнәре ясыйлар;".

Түбәндәге эчтәлектә 6 пункт өстәргә:

"6. Хезмәт органнары һәм эш белән тәэмин итү органнары җибәргән гражданны эшкә алганда эш бирүче эш белән тәэмин итү хезмәтенә, гражданны эшкә алу көнен күрсәтеп, биш көн эчендә

юлламасын кире кайтара.

Хезмәт органнары һәм эш белән тәэмин итү органнары җибәргән гражданны эшкә алудан баш тарткан очракта, эш бирүче эш белән тәэмин итү хезмәтенең юлламасында гражданның мөрәҗәгать иткән көне һәм эшкә алудан баш тартуның сәбәбе турында билге ясап юлламаны гражданга кире кайтара".

17 статья. 29 статьяга түбәндәге эчтәлектә 5 пункт өстәргә:

"5. Эш бирүче хезмәт органнары һәм эш белән тәэмин итү органнары өстеннән югарырак органнарга, шулай ук хөкем тәртибендә шикаять белдерә ала".

18 статья. 30 статьяның 1 пунктындагы беренче һәм икенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Хезмәт шартнамәсе өзелгән гражданнар хезмәт турында законнар нигезендә гарантияләр һәм компенсация түләүләре алалар.

Дәүләт эшсезләргә түбәндәгеләрне гарантияли:".

2 пунктны төшереп калдырырга.

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Гражданның билгеләнгән тәртиптә стипендия, эшсезлек пособиесе алган, түләүле җәмәгать эшләрендә катнашкан вакыты, шулай ук хезмәт органнары һәм эш белән тәэмин итү органнары юлламасы буенча икенче җиргә күчү һәм эшкә урнашу өчен кирәкле вакыты хезмәт стажын өзми һәм ул гомуми хезмәт стажына кертелә;".

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Теләсә нинди сәбәпләр аркасында эштән азат ителгән һәм

эшсез дип танылган гражданнарга вакытлыча хезмәткә сәләтсез булып торган чор өчен хезмәт органнары һәм эш белән тәэмин итү органнары тарафыннан әлеге категория гражданнарга каралган эшсезлек пособиесе күләмендә, беренче эшсезлек чорында (12 айда) 30 көннән дә артмаган вакыт өчен, вакытлыча хезмәткә сәләтсезлекнең факттагы көннәреннән чыгып, түләү үткәрелә. Вакытлыча хезмәткә сәләтсезлек чорына түләү Эш белән тәэмин итүнең дәүләт фонды хисабыннан һәм аның акчалары чикләрендә башкарыла.

Әгәр гражданнар мәгълүм сәбәпләр аркасында эштән азат ителгәннән соң бер ай эчендә хезмәткә вакытлыча сәләтсез дип табылсалар, һәм бу чор бер айдан да артса, вакытлыча хезмәткә сәләтсез чор өчен элеккеге эш урынындагы яисә элеккеге эш урыны хокукларын үаенә алган эш урынындагы җәмгыяви иминлек фонды хисабыннан түләнә.

Предприятие ябылу аркасында хезмәт шартнамәсе юкка чыгарылган хатын-кызларны, югары, махсус урта уку йортларын, техник һөнәр училищеларын бетергәннәрне эшкә урнаштырырга мөмкин булмаса, аларның йөклелек яисә бала табу сәбәпле хезмәткә сәләтсез чорлары өчен яшәү урынындагы хезмәт органнары һәм эш белән тәэмин итү органнары тарафыннан отпускларының барлык көннәре өчен дә Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең минималь күләмендә түләнә, әгәр эштән азат ителгәннән соң (укып бетергәннән соң) бу хатын-кызлар эшсез дип табылган көнгә кадәр 12 айдан да артык вакыт узмаса, киләчәктә бу акчалар җәмгыяви иминлек фонды тарафыннан кире кайтарыла. Бу очракта эштән азат ителгән (укуын бетергән) көннән алып йөклелек өчен яисә бала тапкан өчен отпуск бирелгән көнгә кадәр вакыт 12 айдан да артмаска тиеш. Җәмгыяви иминлек

фондыннан акчалар квартал саен кире кайтарыла.

Эшсез гражданнарның вакытлыча хезмәткә сәләтсез булуы яисә йөклелек һәм бала табу аркасында хезмәткә сәләтсезлеге мәгълүм үрнәктәге сырхауханә документы (хезмәткә сәләтсезлек турында документ) тарафыннан раслана;".

3,4 һәм 5 пунктларны 2,3 һәм 4 пунктлар дип санарга.

19 статья. 31 статьяның беренче һәм икенче өлешләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Предприятиене ябу, үзгәртеп кору, эш урыннарын (штатларны) кимәтү аркасында предприятиедән, учреждениедән, оешмадан эшеннән азат ителә торган гражданнарга хезмәт шартнамәсен өзгән вакытта хезмәт турындагы законнар нигезендә гарантияләр һәм компенсацияләр бирелә.

Уртача айлык хезмәт хакын түләү 6 айга кадәр арттырыла:

үз тәрбиясендә 3 яшьтән 16 яшькә кадәрге ике һәм аннан да күбрәк баласы булган, хезмәткәрләр санын (штатларны) кимәтү аркасында предприятие, учреждение, оешма ябылу сәбәпле эштән азат ителгән хатын-кызларга эшкә урнашканчы;

предприятие, учреждение, оешма тулысынча бетерелгән очракта, үз тәрбиясендә 16 яшькә кадәрге баласы булган ялгыз аналарга, йөкле хатыннарга, 3 яшькә кадәрге баласы булган хатын-кызларга эшкә урнашканчы.

Уртача хезмәт хакыннан билгеләнгән түләүләр чорында алда күрсәтелгән хезмәткәрләрнең өзлексез эш стажы саклана".

Өченче һәм дүртенче өлешләрне төшереп калдырырга.

20 статья. 32 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 2 пункт өстәргә:

"2. Өлгереше канәгатьләнерлек булмаган очракта яисә сәбәпсез дәрес калдырганнарга стипендия киметелергә яисә бөтенләй туктатылырга мөмкин".

21 статья. 33 статьядагы 1 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Теләсә нинди сәбәпләр аркасында эштән азат ителгән эшсез гражданнарга (монда Ш төркем гариплэр дә керә) соңгы эш урынында аздактагы өч айда түләнгән уртача хезмәт хакыннан процент чагыштырмасында пособие билгеләнә, әгәр алар эш эзләүче буларак теркәлгән көнгә кадәр 12 ай дәвамында кимендә 12 атна буена тулы эш көне (атнасы) яисә тулы булмаган эш көне (атнасы) тулы булган эш көненә (атнасына) күчергәндә 12 атна буе эшләсәләр;".

2 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

"Эшсезлек пособиесе минималь хезмәт хакы күләмендә билгеләнгән гражданнарга әлеге пособие алар тәрбиясендәге һәр кеше саен - 10 % ка (гаиләдә берләнбер туйдыручы булып саналган эшсезләргә - 20%ка) арта;".

Статьяга түбәндәге эчтәлектәге 4 пункт өстәргә:

"4. Эшсезлек пособиесеннән салым салу турында гамәлдәге законнар нигезендә керем салымы алына".

22 статья. 34 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип саналган гражданнарга эшсезлек пособиесе түләнә;".

2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян

итәргә:

"2. Эшсезлек пособиесен билгеләү турында карар гражданны әлеге Законның 3 статьясында билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану хакындагы карар белән бергә кабул ителә. Пособие түләү вакыты, әлеге Законда каралган очраклардан тыш, 18 ай дәвамында суммар күләме 12 айдан да артмаска тиеш;".

3 пунктны төшереп калдырырга.

4 пунктны 3 пункт дип исәпләргә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Эшсез хезмәт органнары һәм эш белән тәэмин итү органнары билгеләнгән вакытта кимендә айга ике мәртәбә яңадан теркәлү узса, эшсезлек пособиесе айга ике мәртәбәдән дә ким түләнми;".

5 пунктны 4 пункт дип исәпләргә.

<u>23 статья.</u> 35 статьяда "СССРда дәүләт пенсияләре турында", "ССР Союзы" дигән сүзләрне "Россия Федерациясендә дәүләт пенсияләре турында", "Россия Федерациясенең" дигән сүзләр белән алмаштырырга.

1 пунктка түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац өстәргә:

"Эшсезлек пособиесен түләүнең гомуми вакыты 36 ай дәвамында суммар күләмдә 24 айдан да артмаска тиеш;".

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Хезмәт органнары һәм Эш белән тәэмин итү органнары тәкъдиме буенча, хезмәт эшчәнлегендәге эш стажының өзек булуына да карамастан, картлык нәтиҗәсендә тулы пенсиягә чыгарлык эш стажына ия булган (ташламалы пенсияне дә исәпкә алып) эшсез гражданнарга аларның ризалыгы белән вакытыннан алда пенсия эш-

ләнергә мөмкин, әмма бу гамәл пенсиягә чыгуның законнарда билгеләнгән вакытыннан ике елдан да иртәрәк башкарылмаска тиеш".

24 статья. 37 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

" 37 статья. Башка төр эшсезләр өчен пособие күләме

Беренче мәртәбә эш эзләүче, озак эшләми торганнан соң (бер елдан күбрәк) хезмәт эшчәнлеген дәвам иттерергә омтылган гражданнарга, шулай ук теләсә нинди сәбәпләр аркасында эштән азат ителгән, әмма эшсез калганчы 12 ай дәвамында 12 атна эше булмаган гражданнарга законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең минималь хакы күләмендә пособие түләнә.

Хезмәт органнары һәм эш белән тәэмин итү органнары юлламасы буенча уку йортларында һөнәргә өйрәнүне һәм яна төр һөнәргә өйрәнүне тәмамлаган һәм билгеләнгән тәртиптә эшсез дип табылган гражданнар пособие алырга хаклы, пособиенең беренчел күләме уку чорындагы стипендиядән ким булмаска тиеш".

25 статья. 38 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"38 статья. Эшсезлек буенча пособие түләүне туктатып тору һәм туктату

1. Эшсезлек пособиесен түләү түбәндәге очракларда туктатыла:

эшсез эшкә урнашкач;

хезмәт органнары һәм эш белән тәэмин итү органнары юлламасы нигезендә, стипендия түләп, һөнәргә өйрәнү, белгечлеген күтәрү яисә яңа һөнәргә әйрәнү узса;

эшсезлек пособиесен түләүнең билгеләнгән вакыты тәмамлан-

са;

пособиене ялган юл белән алса;

эшсезлек пособиесе алучы хөкем карары нигезендә ирегеннән мәхрүм ителсә яисә мәҗбүри дәвалануга җәлеп ителсә;

пенсия турында законнар нигезендә пенсия билгеләнсә (III төркем гарипләр пенсиясеннән тыш);

эшсезлек чорында яраклы эштән баш тартса.

2. Эшсезлек пособиесен түләү түбәндәге очракларда өч айга кадәр вакытка кичектерелергә мөмкин:

хезмәт дисциплинасын бозган өчен һәм хезмәт турындагы законнарда каралган башка урынсыз гамәлләре өчен эштән азат ителсә;

эшсез даими яшәү урынында озак вакыт (бер айдан да артык) булмаса.

Эшсезлек пособиесен түләүнең кичектерелгән вакыты эшсезлек пособиесен түләүнең гомуми чорына кертелә.

3. Эшсезлек пособиесен түләү түбәндәге очракларда өч айга кадәр туктатылып торырга мөмкин:

эшсез, хезмәт органнарына һәм эш белән тәэмин итү органнарына хәбәр итмичә генә, вакытлы эшкә яисә тулы булмаган эш көнле (атналы) эшкә урнашса;

эшсез буларак теркәлү һәм яңадан теркәлү шартларын бозса.

Эшсезлек пособиесен түләү туктатылып торган вакыт эшсезлек пособиесе түләүнең гомуми чорына кертелә.

4. Эшсез хезмәт органнары һәм эш белән тәэмин итү органнары юлламасы буенча яисә, аларга хәбәр итеп, вакытлы эшкә урнашу, вакытлыча хезмәткә сәләтсезлеге, башка сәбәпләр аркасын-

да эшсезлек пособиесен түләү туктатылып торган очракларда эшсезлек пособиесен түләү туктатылып торган вакыт эшсезлек пособиесен түләүнең гомуми чорына кертелми.

5. Эшсезлек пособиесенең күләме түбәндәге очракларда өч ай буена 50%ка киметелергә мөмкин:

хезмәт органнары һәм эш белән тәэмин итү органнары җибәргәннән соң өч көн буена, эш бирүчегә барып, эшкә урнашу турында сәбәпсез сөйләшмәсә;

хезмәт органнарына һәм эш белән тәэмин итү органнарына эшкә (укуга) юллама алырга килүдән сәбәпсез баш тартса.

Эшсезлек пособиесен түләүне туктату, кичектерү, туктатып тору яисә аның күләмен киметү турында карар, эшсезгә хәбәр иткәннән соң,хезмәт органнары һәм эш белән тәэмин итү органнары тарафыннан кабул ителә, һәм бу карар хакында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин".

<u>26 статья.</u> 43 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"<u>43 статья.</u> Әлеге Законны бозган өчен эш бирүчеләрнең җаваплылыгы

Әлеге Законның 28 статьясындагы 2,3 һәм 4 пунктларын бозуда гаепле эш бирүчеләр законнарда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең 50 дән алып 100 минималь күләменә кадәр хөкем тәртибендә салынган штраф рәвешендә административ җаваплылыкка тартыла".

<u>27 статья.</u> 45 статьядагы "1 мең сумнан 10 мең сумга кадәр" дигән сүзләрне "хезмәт өчен түләүнең 50 дән алып 100 минималь күләменә кадәр" дигән сүзләр белән алмаштырырга.

<u>28 статья.</u> Закондагы "халык депутатлары җирле Советларының башкарма-бүлү органнары дигән сүзләрне "җирле хакимиятләр"

(17 статьяның 1 абзацы дигән сүзләр белән алмаштырырга, "халык депутатлары җирле Советларының башкарма органнары" дигән сүзләрне "җирле хакимиятләр" (18 статьяның 2 абзацы) дигән сүзләр белән алмаштырырга, "халык депутатларының район (шәһәр) Советларының башкарма комитетлары" дигән сүзләрне "җирле хакимиятләр" (21 статьядагы 2 пунктның 2 абзацы) дигән сүзләр белән алмаштырырга, "башкарма комитетлар" (27 статьяның 6 абзацы) дип алмаштырырга.

29 статья. Әлеге Закон басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,

1994 елның 20 июле
№2I85-XII